ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЕВЯТЕРНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДЕВӘТЕРНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2024 Девәтернә авылы № 28

«2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитетының 28.07.2023 елның 19 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законнары, “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Прокуратурасының 05.03.2024 елның 02-08-02-2024/49 номерлы күрсәтмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитетының 28.07.2023 ел 19 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктчасын өстәргә:

«1.1. Әлеге муниципаль программа индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм "Һөнәри керемгә салым" махсус салым режимын кулланучы физик затларга кагыла».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында https://agryz.tatarstan.ru веб-адрес буенча Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль

районының Девәтернә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районының Девәтернә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Э.Э. Ганиев